РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» 02 2019 ел №150

ТР Ютазы мунииипаль районында Туберкулез, ВИЧ-инфекция белән көрәш буенча территориаль ведомствоара комиссия турында нигезләмәне һәм аның составын раслау турында

Россия Федерациясенең 1999 елның 30 мартындагы "Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында"гы 52-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә туберкулез таралуны кисәтү турында", "Россия Федерациясендә кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ-инфекция) китереп чыгара торган авыруларның таралуын кисәтү турында" гы Федераль законнарын үтәү, муниципаль районда яшәүчеләр арасында туберкулез, ВИЧ-инфекция, башка социаль әһәмияттәге авырулар белән авыручыларны профилактикалау, иртә ачыклау һәм аларның үсешен киметү буенча кичектергесез чаралар күрү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты карар итә:

1. Расларга:

1.1. "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә туберкулез, ВИЧ-инфекция белән көрәш буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне;

1.2. "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә туберкулез, ВИЧ-инфекция белән көрәш буенча ведомствоара комиссия составын;

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче С.П. Самонина

Д.Т. Волкова

Тел. 2-73-11

Кушымта №1

Ютазы муниципаль районы

Башкарма комитеты Карарына

№____ “___” _________ 2019 ел

“ТР ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ ТУБЕРКУЛЕЗ, ВИЧ-ИНФЕКЦИЯ БЕЛӘН КӨРӘШ БУЕНЧА ВЕДОМСТВОАРА КОМИССИЯ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

1. Туберкулез, ВИЧ-инфекция белән көрәш буенча ведомствоара комиссия (алга таба - комиссия) сәламәтлек саклау учреждениесенең туберкулез, ВИЧ-инфекция белән көрәш мәсьәләләре буенча эшен координацияләү, туберкулез, ВИЧ-инфекция авыруларын профилактикалау һәм кисәтүгә юнәлдерелгән бурычларны хәл итү буенча чараларны планлаштыру һәм санитар-эпидемиологик иминлекне тәэмин итү өчен булдырылган даими эшләүче киңәшмә органы булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, муниципаль хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

бердәм стратегияне формалаштыру һәм туберкулез, ВИЧ-инфекция белән массакүләм авыруларны профилактикалау һәм халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру буенча чаралар эшләүдә катнашу;

туберкулезны, ВИЧ-инфекцияне профилактикалау буенча төп социаль, медицина, икътисадый һәм башка проблемаларны комплекслы өйрәнү;

туберкулез, ВИЧ-инфекция белән көрәш, халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү буенча максатчан программаларны эшләүдә катнашу;

Россия Федерациясе санитария законнарын бозу нәтиҗәсендә гражданнарның сәламәтлегенә салынган зыянны каплау мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләүдә катнашу.

4. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне үтәүне гамәлгә ашыра:

- "ТР Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә халыкның санитар-эпидемиологик иминсезлеге барлыкка килүгә бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итүне оештыру;

- "ТР Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә санитар-эпидемиологик хәл торышын анализлау, аны үзгәртү фаразы һәм Россия Федерациясенең санитария закончалыгын үтәү буенча тәкъдимнәр;

- массакүләм мәгълүмат чаралары аша комиссия эшчәнлегенең юнәлешләре һәм нәтиҗәләре турында халыкка мәгълүмат җиткерү.

5. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

- нинди ведомствога каравына һәм оештыру-хокукый формасына бәйләнмәгән рәвештә, предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләреннән туберкулезның таралуын кисәтү буенча чараларны тормышка ашыру буенча кирәкле материалларны соратып алырга;

- үз утырышларында нинди ведомствога каравына һәм оештыру-хокукый формаларына бәйләнмәгән рәвештә җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләренең туберкулез, ВИЧ-инфекция белән авыручыларны профилактикалауга һәм халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашырулары турында тыңларга;

- җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына, предприятие, учреждение һәм оешма җитәкчеләренә туберкулез, ВИЧ-инфекция белән авыручылар санының торышы, аларның үзгәрешен фаразлау, профилактика чаралары, аларга каршы көрәш чаралары комплексы турында хәбәр итәргә;

- тиешле органнарга туберкулез белән авыру яисә ВИЧ-инфекция таралуда гаепле кешеләрне җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне хәл итү өчен мәгълүмат бирергә.

6. Комиссиянең эш тәртибе.

6.1. Комиссия вәкаләтле кешеләр нигезендә формалаша. Комиссия составына җирле үзидарә органнары вәкилләре, шулай ук килешү буенча башка органнар һәм оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, галимнәр, белгечләр һәм җәмәгать эшлеклеләре кертелә. Комиссия әгъзалары үз эшчәнлекләрен иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра һәм аның утырышларында катнаша. Кирәк булган очракта, комиссия утырышына

прокуратура, суд, эшмәкәрлек структуралары, иҗтимагый оешмалар вәкилләре чакырыла ала. Комиссия утырышлары кварталга кимендә 1 тапкыр уздырыла.

6.2. Комиссия үз эшчәнлеген комиссия рәисе раслаган эш планы нигезендә гамәлгә ашыра. Комиссия утырышын комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары алып бара.

6.3. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы була. Комиссиянең барлык карарлары комиссия әгъзаларының гомуми составының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

6.4. Комиссия карарлары утырыш беркетмәләре рәвешендә рәсмиләштерелә, алар утырышта рәислек итүче тарафыннан расланa һәм комиссия секретаре тарафыннан имзалана. Карарлар нинди ведомствога каравына һәм оештыру-хокукый формасына карамастан, кызыксынган предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләре игътибарына тиешле өземтә рәвешендә җиткерелә. Комиссия карарлары рекомендация характерында була.

7. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү "Урыссу үзәк район хастаханәсе" ДАССУга йөкләнә.

Кушымта №2

Ютазы муниципаль районы

Башкарма комитеты Карарына

№____ “___” _________ 2019 ел

**ТР Ютазы муниципаль районында туберкулез, ВИЧ-инфекция белән көрәш буенча ведомствоара комиссия составы**

Волкова Д.Т. - ТР Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль сораулар буенча урынбасары, *комиссия рәисе (килешү буенча*);

Алатырева Г.Г. - Роспотребнадзор Идарәсенең ТР буенча Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарында территориаль бүлеге начальнигы урынбасары, *комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча*);

Әхмәрова Г.А. – Роспотребнадзорның ТР буенча Идарәсенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарындагы территориаль бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече, *сәркатип (килешү буенча)*;

*Комиссия әгъзалары :*

Хөсәенова А.Н. - ТР Ютазы муниципаль районының “Мәдәният бүлеге” МКУ начальнигы *(килешү буенча);*

Садриева М.Н. - ТР Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигы *(килешү буенча*);

Шакирова С.З. - “Урыссу үзәк район хастаханәсе” ДАССУның баш табибы *(килешү буенча);*

Нигъмәтуллин А.А. – ТР Ютазы районы буенча Эчке эшләр министрлыгы бүлеге начальнигы (*килешү буенча).*

Гыйлаҗева Г.М. - ТР Ютазы муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” МКУ начальнигы *(килешү буенча)*.

Крюкова Е.В. - “Ютазы таңы” – “Ютазинская новь” газетасының баш мөхәррире.